**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында гражданнар җыены карары нәтиҗәләре турында

25.10.2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 124 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында 2024 елның 25 октябре 17.00 сәг. узган гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде. Җыенда “2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Тихоново авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә, ә күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр бирелә торган түләүне 50%ка киметеп, 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорау каралды..

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тихоново авылында асфальт һәм бетон түшәмәле юлларны төзекләндерү һәм чокырларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм чыгару системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина өчен тирәннән су алу насосы сатып алу);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, триммер сатып алу);

4) коймаларны ремонтлау, кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (авыл зиратында койма монтажлау);

5) урамнарга яктырту җайланмасы алу (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмәгә ярашлы: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 538 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 283 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«риза» - гражданнар җыенының 283 катнашучысы тавыш бирә;
«каршы» - 0

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. 2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Тихоново авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә, ә күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр бирелә торган түләүне 50%ка киметеп, 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорауга карарны танырга.

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тихоново авылында асфальт һәм бетон түшәмәле юлларны төзекләндерү һәм чокырларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм чыгару системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина өчен тирәннән су алу насосы сатып алу);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, триммер сатып алу);

4) коймаларны ремонтлау, кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (авыл зиратында койма монтажлау);

5) урамнарга яктырту җайланмасы алу (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру)

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Тихоново авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә һәм Менделеевск муниципаль районының

рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Тихоново авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТР Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге башлыгы _____________ А.М. Карманов

(подпись) (расшифровка подписи)